ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«7» 06 2018 г. № 142

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы нигезләмәсен һәм составын раслау турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга тәнгәлләштерү максатларында, 2014 елның 21 июлендәге "Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контроле нигезләре турында" 212-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль законнарга ярашлы рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге "Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында" 906 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Расларга (кушымтада бирелгәнчә):

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы турында Нигезләмәне;

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы составын.

2.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисенә җәмәгать башлангычында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советы рәисе вәкаләтләрен бирергә.

3.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгының 2013 елның 7-нче ноябрьдәге "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы Нигезләмәсен һәм составын раслау турында" 139-нче номерлы карарының көчен югалтуын танырга.

4.Элеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин

Балтач муниципаль район башлыгының 2019 елның ___ нче 07. 06 ___ 142 нче номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы турында Нигезләмә

## I. Г омуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы (алга таба - Иҗтимагый совет) киңәшләшү органы булып тора, ул Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнарның хокук һәм ирекләрен һәм җәмәгать берләшмәләре, дәүләтнеке һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларның тиңдәшле өлкәдә сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда хокукларын, гражданнарның сыйфатлы хезмәт күрсәтүләргә, аларның нәтиҗәлелегенә һәм куркынычсызлыгына хокукларын тормышка ашыру, халыкка хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек системасын камилләштерү белән бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

1.3. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә,федеральконституционзаконнарга,федеральзаконнарга,Россия Федерациясе Президенты указлары һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары киңәш бирү характерында була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычында гамәлгә ашыра.

1.6. Иҗтимагый совет эше ирекле нигездә, ачыклык һәм хезмәттәшлек принципларында һәм катгый рәвештә гамәлдәге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хокукый актлары нигезендә төзелә.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданлык җәмгыяте институты, җирле үзидарә органнары вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынучанлыгы нигезендә гамәлгә ашыра.

## II. Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары булып тора:

-гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокук һәм ирекләрен һәм җәмәгать берләшмәләре, дәүләтнеке һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларның тиңдәшле өлкәдә сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда хокукларын яклау;

-җәмәгать, һөнәр һәм иҗат берләшмәләре вәкилләрен эшчәнлекнең тиңдәшле өлкәсенә кагылган сораулар буенча сәясәтнең төп юнәлешләрен

эшләүгә җәлеп итү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принципларын тормышка ашыру;

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып тора:

- район территориясендә эш итүче җирле үзидарә һәм җәмәгать оешмалары органнарының, дини берләшмәләр, һөнәр берлекләре һәм гражданнарның башка төрле берләшмәләренең үзара бәйләнешләре механизмын камилләштерү;

-район тормышы һәм эшчәнлегенең иң мөһим мәсьәләләре буенча карарлар эшләүгә, анализлау һәм бәяләүгә гражданнарның катнашуын тәэмин итү;

- район территориясендә эш итүче җирле үзидарә һәм җәмәгать оешмалары органнарының, дини берләшмәләр, һөнәр берлекләре һәм гражданнарның башка төрле берләшмәләре мәгълүмати-аналитик эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү;

-тормыш һәм эшчәнлекнең иң әһәмиятле мәсьәләләре буенча һәм районда иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкка ирешүдә төрле социаль төркемнәрнең мәнфәгатьләрен яраштыру;

- җирле әһәмияттәге аеруча социаль яктан мөһим булган мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары кабул иткән карарларны тикшерү;

-районда яшәүчеләрнең җирле үзидарә органнары белән нәтиҗәле элемтәсен тәэмин итү;

-иҗтимагый фикер формалаштыруга булышлык итү, район тормышы һәм эшчәнлегенең аерата мөһим мәсьәләләре буенча системалы рәвештә җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү;

-халыкның төрле социаль төркемнәренең, барлык милек формаларындагы предприятиеләрнең һәм җирле үзидарә органнарының мәнфәгатьләрен яраштыру механизмын камилләштерү;

-район тормышындагы мөһим социаль-икътисади, хокукый һәм сәяси мәсьәләләрне аеруча оптималь хәл итү буенча тәкъдимнәр эшләү;

- җәмгыятьтә килеп чыккан процесслар хакында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгына мәгълүмат ирештерү, тәкъдимнәр эшләү;

- тиңдәшле өлкәдә сәясәтне камилләштерү буенча тәкъдимнәр хәзерләү;

-законнарда каралган очракларда эшчәнлекнең тиңдәшле өлкәсе мәсьәләләренә
караган муниципаль норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул ителгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында җәмәгатьчелекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча хәбәрдарлыгын (мәгълүматлылыгын) арттыру;

-Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалары, федераль законнар нигезендә аерым ачык вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка орган һәм оешмаларның эшчәнлегенә җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру;

-мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан күрсәтелгән

хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү.

2.3. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итү максатларында Иҗтимагый совет хокуклы:

-күрсәтелгән органнар компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарына таләпләр (запрослар) җибәрергә. Иҗтимагый совет таләпләре әлеге Нигезләмәнең 2.1. һәм 2.2. пунктларында күрсәтелгән аның максатларына һәм бурычларына туры килергә тиеш. Җирле үзидарә органнары Иҗтимагый совет запрослары буенча аңа үзенең вәкаләтләрен үтәү өчен зарур булган мәгълүматларны бирергә тиешләр, шул исәптән документлар һәм материаллар рәвешендә, дәүләт һәм башка федераль закон белән саклана торган серне тәшкил итүче мәгълүматлардан гайре. Иҗтимагый советның запросы җибәрелгән вазыйфаи зат таләп алынган көннән соң 30 көннән дә соңармыйча аңа җавап бирергә бурычлы, ә Иҗтимагый совет тәгаенләгән гадәттән тыш очракларда - 14 көннән дә соңга калмыйча. Җавап җибәрелгән вазыйфаи зат тарафыннан яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан имзаланырга тиеш;

-законда каралган очракларда муниципаль норматив хокукый актлар һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары проектларына иҗтимагый экспертиза уздырырга;

-җирле үзидарә органнары тарафыннан законнарны бозу турында бәяләмәләр бирергә һәм күрсәтелгән бәяләмәләрне компетентлы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яки вазыйфаи затларга җибәрергә;

-җәмгыять тормышының төрле мәсьәләләре буенча инициативалар белән чыгарга, җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә;

- массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы үз эшчәнлегенең нәтиҗәләре хакында район халкына мәгълүмат ирештерергә.

- җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру

2.4. Иҗтимагый советның максатлары, бурыч һәм вәкаләтләре үзгәрүе ихтимал һәм аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендәге икътисади, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

## III. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет аның рәисе, рәис урынбасары, сәркатибе һәм әгъзалары составында гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке һәм коммерциячел булмаган оешмалар тәкъдимнәре нигезендә төзелә. Иҗтимагый советның персональ составы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

3.2. Иҗтимагый совет ирекле катнашу нигезендә 20 кеше составында төзелә.

3.3. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләт срогы советның беренче утырышы көненнән өч елдан соң чыга.

3.4. Иҗтимагый совет составына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә эш итүче җәмәгать оешмалары, һөнәр берлекләре һәм гражданнарның бүтән берләшмәләре вәкилләре керә.

Иҗтимагый совет составына шулай ук бүтән социаль юнәлештәге кәсәбәчелексез оешмалар вәкилләре булып торган гражданнар керергә мөмкин. Бу вакытта аларның Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләрне тикшерү

өчен зарур булган профессиональ сыйфатлары, шул исәптән тиндәшле белемнәре, әлеге өлкәдәге эш тәҗрибәсе исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артмаган санда элек Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт

вазыйфаларын алмаштырган затлар керергә мөмкин.

3.5. Россия Федерациясенең унсигез яшькә җиткән гражданы Иҗтимагый совет әгъзасы булырга мөмкин.

Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы затлар, хөкем карары нигезендә хокуктан файдалануга сәләтсез дип табылган затлар, хөкем ителгәнлеге капланмаган яисә бетерелмәгән затлар, шулай ук 2005 елның 4 апрелендәге “Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында” 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмаучы башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар.

3.6. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасары Иҗтимагый советның беренче утырышында совет әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән алар өчен Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш биргәндә сайланган булалар. Иҗтимагый совет рәисе һәм рәис урынбасарын сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча ачык тавыш бирү юлы белән совет утырышында аны яклап Иҗтимагый совет әгъзалары санының яртысыннан артыгы тавыш биргәндә сайлана. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибен сайлау турындагы карар Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет рәисен яки рәис урынбасарын вазыйфасыннан азат итү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгы мөрәҗәгате буенча карала, шулай ук аларның шәхси гаризалары буенча яисә барлык совет әгъзалары санының биштән бере тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала. Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргәндә карар кабул ителгән булып санала.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракта туктатыла:

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында аның тарафыннан гариза бирелгәндә;

сәламәтлек торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаганда;

судның аңа карата чыгарылган гаепләү карары закон көченә кергәндә;

ул суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә закон көченә кергән суд карары нигезендә билгесез булмаучы дип танылганда;

аның тарафыннан әхлак нормалары тупас бозылганда - утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

нигезле сәбәпсез системалы рәвештә (өч мәртәбәдән артык) Иҗтимагый совет утырышлары эшендә катнашмаганда;

нигезле сәбәпсез системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәләрен үтәмәгәндә;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;

аны Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфасына, дәүләт хезмәтенең федераль вазыйфасына, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт граждан хезмәте яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;

гражданин ике гражданлылыкка ия булганда.

3.8. Иҗтимагый советта әгъзалыкны туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары тәкъдиме буенча, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктында күздә тотылган хәл ачыкланган очракта Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сәламәтлеге буенча, аңа карата гаепләү хөкем карарының закон көченә керүе, Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу аркасында эшчәнлеген гамәлгә ашыра алмау очрагында Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге фактлар турында күрсәтелгән хәлләрнең барлыкка килү көненнән утыз көн срок эчендә Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

3.9. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгы карары нигезендә түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны җинаять кылуда гаепләү;

аңа административ арест (кулга алу) рәвешендә административ җәза билгеләү;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, ышанычлы зат яисә сәяси фирка кандидатының вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәү, шулай ук аның Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатива төркеме составына керүе очрагында.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы хокуклы:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районындагы җирле үзидарә органнары инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда (утырышлар, киңәшмәләр, “түгәрәк өстәлләр” һ.б.да) катнашырга, дәүләт сере булып торган, персональ данныйлар турындагы һәм керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүматларны файдалану белән бәйле федераль законнар нигезендә керү чикләнгән чаралардан гайре;

инициатива тәртибендә анализ язулары, докладлар һәм башка

мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм аларны Иҗтимагый советка җибәрергә;

Иҗтимагый совет рәисе аркылы Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышларын үткәрү тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышларына чакырылучы затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

Иҗтимагый советның әлеге Нигезләмәдә каралган эш тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет тарафыннан төзелә торган экспертлар, эшче төркемнәр, комиссияләр, бүтән эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үзенең эшен, совет рәисе тәкъдим итеп, Иҗтимагый совет утырышында расланган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да ким булмаган санда уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары инициативасы буенча алар тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый акт проектларына һәм законда билгеләнгән очракларда муниципаль норматив хокукый актларга Иҗтимагый советның бәяләмәсен бирү максатларында үткәрелә.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган санда әгъзалар катнашканда тулы хокуклы булып санала. Иҗтимагый совет әгъзасы утырышта үзенең шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаганда көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм үз фикерен алдан ул турыда Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына, яисә Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибенә хәбәр итеп, язмача, факсимиль яки электрон почта аша Иҗтимагый советның бүтән әгъзасына тапшырырга хокуклы. Иҗтимагый совет утырышында катнашучылар санына үзләренең тавышларын советның башка әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын (муниципаль норматив хокукый актларны) Иҗтимагый совет тарафыннан карау аларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органы Иҗтимагый советка җибәргән көннән соң ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Шуның белән бергә алар буенча Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү

максатларында тавыш бирүне үткәрү Иҗтимагый советның барлык әгъзаларыннан сораштыру формасында, сораштыру нәтиҗәләрен Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаганда Иҗтимагый совет рәисе урынбасары имзалаган беркетмәгә кертеп, читтән торып тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин. Мондый тавыш бирү тапшырыла һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең чынлыгын (дөреслеген) һәм аларның документаль раслануын тәэмин итүче почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки бүтән элемтә аша документларны алышу юлы белән үткәрелергә мөмкин. Читтән торып тавыш бирү үткәрелү очрагында аны үткәрү датасына тикле җиде календарь көннән дә соңармыйча рәис урынбасарына, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый советның бәяләмәсе бирелергә тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты (муниципаль норматив хокукый акт) җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары зарурлык булганда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан карала торган муниципаль норматив хокукый акт проекты (муниципаль норматив хокукый акт) буенча өстәмә материалларны һәм мәгълүматны соратып алдыралар. Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе үткәрә, ул булмаган очракта - Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советның аңа йөкләнгән максатлары, бурычлары, вәкаләтләренә ярашлы рәвештә кабул ителгән карарлары тәкъдим итү (киңәш бирү) характерына ия һәм кызыксынучы затлар игътибарына Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яисә Иҗтимагый совет карары буенча бүтән ысул белән җиткерелә.

Иҗтимагый совет эшчәнлеге хакында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының http:// baltasi.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

5.7. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә советның эш планнарын хәзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм Иҗтимагый советка раслауга тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет рекомендацияләрен, беркетмәләрен һәм Иҗтимагый советның башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын тәгаенли;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, советка йөкләнгән максат һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән запросларга, рекомендацияләр, тәкъдимнәр, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләргә имза сала;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.8. Иҗтимагый советның рәис урынбасары:

совет рәисе рәсми рәвештә булмаган вакытта Иҗтимагый совет рәисе функциләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын хәзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртипләрен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисенә раслауга тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе йөкләмәсе буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен зарури булган бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.9. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын хәзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышларының үткәрү урыны һәм вакыты, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмати- белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының организацион үзара бәйләнешләрен, тәэсир итешүләрен тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлегенең документаль-техник тәэмин ителешен гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртипләрен төзүдә катнаша.

5.10. Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга сорауларны әзерләү өчен Иҗтимагый совет әгъзалары эшче төркемнәргә, экспертлар төркемнәренә һәм бүтән эшче төркемнәргә берләшергә, материалларны әзерләүгә Иҗтимагый советның рәис урынбасары белән килештереп Иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне тартырга мөмкин.

5.11. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет карый торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, кәсәбәчелексез оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет каравына кертелүче материаллар . Иҗтимагый советның рәис урынбасарына аларны карау күздә тотылган Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына чаклы ун календарь көннән дә соңармыйча тапшырылырга тиеш. Материалларны тагын да соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яки аның урынбасары белән килештерелә.

5.13. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең техник һәм оештыру ягыннан тәэмин ителешен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советы аппараты тәэмин итә.

## 6.Иҗтимагый совет тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмаларының, федераль законнар нигезендә ачык (халык алдында) аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы бүтән орган һәм оешмаларның эшчәнлегенә җәмәгатьчелек контроле гамәлгә ашырылганда Иҗтимагый советның хокуклары һәм бурычлары

6.1. Иҗтимагый совет җәмәгатьчелек контролен 2014 елның 21

июлендәге “Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контроле нигезләре турында” 212-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган форма һәм тәртипләрдә гамәлгә ашыра.

6.2. Җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашырганда Иҗтимагый совет хокуклы:

- җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашырганда үткәрелә торган чараларның инициаторы, оештыручысы сыйфатында чыгарга, шулай ук үткәрелүче чараларда катнашырга;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм муниципаль оешмалардан, федераль законнар нигезендә ачык (халык алдында) аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка орган һәм оешмалардан җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, дәүләт сере булып торган, персональ данныйлар турындагы мәгълүматларны үз эченә алган һәм керү мөмкинлеге федераль законнар белән чикләнгән мәгълүматтан гайре, соратып алдырырга;

- федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль норматив хокукый актларда күздә тотылган очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларына, федераль законнар нигезендә ачык (халык алдында) аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка орган һәм оешмаларга барырга;

-җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча гомуми йомгак документы хәзерләргә һәм карау өчен аны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль оешмаларына, федераль законнар нигезендә ачык (халык алдында) аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башка орган һәм оешмаларга һәм массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрергә;

-кеше һәм гражданның хокук һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларның хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары ачыкланган очракта җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру барышында алынган материалларны федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча ввәкаләтле вәкилгә, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасындагы кеше хокуклары, бала хокуклары, эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләргә һәм прокуратура органнарына җибәрергә;

-федераль законнарда күздә тотылган очракларда затларның мәгълүм булмаган даирәсе, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларның хокук һәм законлы мәнфәгатьләрен яклап судка мөрәҗәгать итәргә;

- Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклардан файдаланырга.

6.3. Җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашырганда Иҗтимагый совет бурычлы:

-җәмәгатьчелек контроле турында Россия Федерациясе законнарын үтәргә;

- федераль законнарда билгеләнгән җирле үзидарә органнары эшчәнлеге белән бәйле чикләүләрне үтәргә;

- федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары, муниципаль оешмалары, бүтән орган һәм оешмаларының законлы эшчәнлегенә тоткарлыклар ясамаска;

- җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашырганда алынган мәгълүматның, әгәр аны тарату федераль законнар белән чикләнгән булса, яшеренлеген үтәргә;

-җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру буенча үзенең эшчәнлеге һәм контроль нәтиҗәләре хакында 2014 елның 21 июлендәге “Россия Федерациясендә җәмәгатьчелек контроле нигезләре турында” 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәгълүматны халыкка игълан итәргә;

- Россия Федерациясе законнарында каралган башка вазыйфаларны башкарырга.